ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

04.06.2015 № 150

**Татарстан Республикасы тарифлар буенча Дәүләт комитеты дәүләт гражданлык хезмәткәренә коррупциячел хокук бозулар кылуга җәлеп итү максатларында мөрәҗәгать итү фактлары турында эшкә алучы (эш бирүче) вәкиленә хәбәр итү Тәртибе турында**

«Коррупциягә каршы тору турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ санлы Федераль законның 9 маддәсе 5 бүлегенә туры китереп,
боерам:

1. Татарстан Республикасы тарифлар буенча Дәүләт комитеты дәүләт гражданлык хезмәткәренә коррупциячел хокук бозулар кылуга җәлеп итү максатларында мөрәҗәгать итү фактлары турында эшкә алучы (эш бирүче) вәкиленә хәбәр итү Тәртибен расларга.

2. Татарстан Республикасы тарифлар буенча Дәүләт комитетының «Татарстан Республикасы тарифлар буенча Дәүләт комитеты дәүләт гражданлык хезмәткәренә коррупциячел хокук бозулар кылуга җәлеп итү максатларында мөрәҗәгать итү фактлары турында эшкә алучы (эш бирүче) вәкиленә хәбәр итү Тәртибе турында» 2013 елның 3 июлендәге 178 санлы карары үз көчен югалткан дип танырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көннән соң ун көн узгач үз көченә керә.

4. Әлеге боерык үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Рәис вазифаларын башкаручы А.Л.Штром

Татарстан Республикасы
тарифлар буенча Дәүләт
комитетының 2015 елның
4 июнендәге 150 санлы
боерыгы белән расланган

**Татарстан Республикасы тарифлар буенча Дәүләт комитеты дәүләт гражданлык хезмәткәренә коррупциячел хокук бозулар кылуга җәлеп итү максатларында мөрәҗәгать итү фактлары турында эшкә алучы (эш бирүче) вәкиленә хәбәр итү Тәртибе**

1. Татарстан Республикасы тарифлар буенча Дәүләт комитеты дәүләт гражданлык хезмәткәренә коррупциячел хокук бозулар кылуга җәлеп итү максатларында мөрәҗәгать итү фактлары турында Татарстан Республикасы тарифлар буенча Дәүләт комитеты дәүләт гражданлык хезмәткәре ( алга таба- дәүләт хезмәткәре ) тарафыннан әлеге Тәртипнең 1 кушымтасы нигезендә язма рәвештә Татарстан Республикасы тарифлар буенча Дәүләт комитетында коррупциячел һәм башка хокук бозуларны булдырмый калу буенча эш башкару өчен җаваплы (эш бирүче) вәкиленең вәкаләтле затына (алга таба- вәкаләтле зат) хәбәр итү кәгазен (алга таба- хәбәр итү кәгазе) тапшыру яисә шундый хәбәр итү кәгазен почта аша җибәрү юлы белән башкарыла.

2. Дәүләт хезмәткәре коррупциячел хокук бозулар кылуга җәлеп итү максатларында нинди дә булса затларның мөрәҗәгать ителгән барлык очраклары турында аңа мөрәҗәгать ителгән көннән соң килгән эш көненнән дә соңга калмыйча эшкә яллаучы (эш бирүче) вәкиленә хәбәр итәргә тиеш.

Дәүләт хезмәткәре командировкада, ялда, хезмәт итү урыныннан тыш башка урында булса, ул бу турыда кичекмәстән хезмәт урынына килгән мизгелдән үк эшкә яллаучы (эш бирүче) вәкиленә хәбәр итәргә тиеш.

3. Хәбәр итү кәгазендә яктыртылырга тиешле мәгълүматлар исемлегенә түбәндәгеләр керә:

- хәбәр итү кәгазен юнәлткән дәүләт хезмәткәренең фамилиясе, исеме, атасының исеме, тору урыны һәм телефоны;
- хезмәт вазифаларын үтәүгә бәйле дәүләт хезмәткәренә коррупциячел хокук бозулар кылуга җәлеп итү максатларында мөрәҗәгать итү очрагы ачыклану шартын тасвирлау (көне, урыны, вакыты, башка шартлар). Дәүләт хезмәткәре тарафыннан әлеге Тәртипнең 10 пунктында күрсәтелгән хәбәр итү кәгазе юнәлтелгән очракта коррупциячел хокук бозулар кылуга җәлеп итү максаты куелган дәүләт хезмәткәренең фамилиясе, исеме, атасының исеме, хезмәт вазифасы күрсәтелә.
- үзенә мөрәҗәгать иткән затлар соравы белән дәүләт хезмәткәре кылырга тиеш булган коррупциячел хокук бозулар турында тулы мәгълүмат;
- дәүләт хезмәткәрен коррупциячел хокук бозулар кылуга җәлеп итәргә теләгән физик (юридик) зат турында барлык мәгълүм мәгълүматлар (фамилиясе,

исеме, атасының исеме,  хезмәт вазифасы һ.б.);

- дәүләт хезмәткәрен коррупциячел хокук бозуларга җәлеп итү ысулы (сатып алу, куркыту, көчләү, вәгъдә итү, шантаж һ.б);

- дәүләт хезмәткәрен коррупциячел хокук бозулар кылуга җәлеп итү шартлары (телефоннан сөйләшү, шәхси  очрашу, хат белән җибәрү һ.б.), шулай ук коррупциячел хокук бозулар кылуга җәлеп иткән затның тәкъдимен кире кагу (килешү) турында мәгълүмат;

- дәүләт хезмәткәре тарафыннан хәбәр итү кәгазен тутыру  көне;

- дәүләт хезмәткәре тарафыннан тутырылган хәбәр итү кәгазенә кул кую;

4. Татарстан Республикасы тарифлар буенча Дәүләт комитеты дәүләт гражданлык хезмәткәренә  коррупциячел хокук бозулар кылуга җәлеп итү максатларында мөрәҗәгать итү фактлары турында хәбәр итү кәгазе килгән көнендә үк теркәү кенәгәсендә (алга таба- теркәү кенәгәсе) мәҗбүри теркәлеп куелырга тиеш. Теркәү кенәгәсе әлеге Тәртипнең 2 кушымтасы нигезендә төзелергә, битләренә тәртип саннары куелып, тегелергә, шулай ук Татарстан Республикасы тарифлар буенча Дәүләт комитеты мөһере белән расланырга тиеш.

Теркәү кенәгәсен  алып  бару  вәкаләтле затка йөкләнә.

5. Вәкаләтле зат хәбәр итү кәгазен  теркәү кенәгәсенә  теркәп куйганнан соң, хәбәр итү кәгазен тапшырган дәүләт гражданлык хезмәткәренә,  әлеге хәбәр итү кәгазен кабул иткән зат турындагы мәгълүматларны, алу көнен һәм вакытын күрсәтеп һәм алганга кул куйдыртып, талон- уведомление тапшыра.

Талон-уведомление ике өлештән тора: талон-уведомление корешогы һәм талон-уведомление ( әлеге Тәртипнең 3 кушымтасы).

Тутырылганнан соң талон-уведомление корешогы вәкаләтле затта кала.

Хәбәр итү кәгазе почта аша җибәрелгәндә, дәүләт гражданлык хезмәткәренә талон-уведомление шулай ук почта аша заказлы хат белән җибәрелә.

Хәбәр итү кәгазен теркәүдән баш тарту, шулай ук талон-уведомление бирмәү рөхсәт ителми.

6. Хәбәр итү кәгазе теркәү кенәгәсенә теркәлеп куелганнан соң, аның эчтәлеген тәшкил иткән  мәгълүматларны алга таба тикшерүне оештыру максатында ул Татарстан Республикасы тарифлар буенча Дәүләт комитеты рәисенә (яисә аның вазифаларын  башкаручыга) тапшырыла.

7. Алынган  мәгълүматларның конфиденциальлеген  вәкаләтле зат тәэмин итә.

8. Дәүләт хезмәткәренә хезмәт вазифаларын үтәү белән бәйле коррупциячел хокук бозулар кылуга җәлеп итү максатларында мөрәҗәгать итү очраклары турындагы мәгълүматларны яисә нинди булса да затларның башка дәүләт хезмәткәренә  коррупциячел хокук бозулар кылуга җәлеп итәргә теләп мөрәҗәгать итүләре буенча  мәгълүм булган фактларны тикшерүне оештыру вәкаләтле зат тарафыннан  Татарстан Республикасы тарифлар буенча Дәүләт комитеты рәисе (яисә аның вазифаларын үтәүче зат) кушуы буенча Татарстан Республикасы Прокуратурасына, Татарстан Республикасы буенча эчке эшләр идарәсе министрлыгына, Татарстан Республикасы  буенча Федераль куркынычсызлык хезмәте идарәсенә хәбәр итү кәгазьләрен юнәлтү, хәбәр  итү кәгазен тапшырган дәүләт хезмәткәре, хәбәр итү кәгазендә күрсәтелгән  зат белән

әңгәмәләр үткәрү, хәбәр итү кәгазендә бәян ителгән мәгълүматлар буенча дәүләт хезмәткәреннән аңлатма алу юлы белән башкарыла.

9. Вәкаләтле зат тарафыннан хәбәр итү кәгазе Татарстан Республикасы Прокуратурасына, Татарстан Республикасы буенча эчке эшләр идарәсе министрлыгына, Татарстан Республикасы Федераль куркынычсызлык хезмәте идарәсенә теркәү кенәгәсендә теркәлгән көннән 10 көннән дә соңга калмыйча юнәлтелә.

10. Дәүләт хезмәткәренә хезмәт вазифаларын үтәү белән бәйле нинди булса да затларның башка дәүләт хезмәткәренә коррупциячел хокук бозулар кылуга җәлеп итү максатларында мөрәҗәгать итү фактлары билгеле булса, ул бу турыда эшкә алучы (эш бирүче) вәкиленә билгеләнгән Тәртипкә охшаш тәртиптә хәбәр итәргә хокуклы.

11. Дәүләт хезмәткәре тарафыннан «Коррупциягә каршы тору турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ санлы Федераль законның 9 маддәсе 1 бүлегендә каралган хезмәт вазифаларын үтәмәү аны дәүләт хезмәтеннән азат итүгә яисә Россия Федерациясе законнары нигезендә башка җаваплылык төрләренә тартуга китергән хокук бозу булып тора.

Татарстан Республикасы тарифлар буенча Дәүләт комитетының 2015 елның 4 июнендәге 150 санлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы тарифлар буенча Дәүләт комитеты дәүләт гражданлык хезмәткәрен коррупциячел хокук бозулар кылуга җәлеп итү максатларында мөрәҗәгать итү фактлары турында эшкә алучы (эш бирүче) вәкиленә хәбәр итү Тәртибенә 1 кушымта

________________________________________________
(Ф,И.А., эшкә алучы ( эш бирүче) вәкиле вазифасы)

________________________________________________
(дәүләт органы атамасы)

________________________________________________
(Ф.И.А., дәүләт гражданлык хезмәткәре вазифасы, тору урыны, телефоны)

## Татарстан Республикасы тарифлар буенча Дәүләт комитеты дәүләт гражданлык хезмәткәренә коррупциячел хокук бозулар кылуга җәлеп итү максатларында мөрәҗәгать итү фактлары турында эшкә алучы ( эш бирүче) вәкиленә ХӘБӘР ИТҮ КӘГАЗЕ

Түбәндәгеләрне
хәбәр итәм:

1\.
______________________________________________________________________________
______________________________________________________________________________
____________________________________________________________________________
( хезмәт вазифаларын үтәүгә бәйле дәүләт гражданлык хезмәткәренә коррупциячел хокук бозулар кылуга җәлеп итү максатларында мөрәҗәгать итү очрагы ачыклану шартларын тасвирлау)

2\.
______________________________________________________________________________
______________________________________________________________________________
______________________________________________________________________________
( дәүләт гражданлык хезмәткәренә мөрәҗәгать иткән затлар соравы белән дәүләт хезмәткәре кылырга тиеш булган коррупциячел хокук бозулар турында тулы мәгълүмат)

3\.
______________________________________________________________________________
______________________________________________________________________________
____________________________________________________________________________
(дәүләт гражданлык хезмәткәрен коррупциячел хокук бозулар кылуга җәлеп иткән физик (юридик) зат турында барлык мәгълүм мәгълүматлар)

4\.
______________________________________________________________________________
______________________________________________________________________________
______________________________________________________________________________
(дәүләт гражданлык хезмәткәрен коррупциячел хокук бозуларга җәлеп итү ысулы һәм шарты, шулай ук коррупциячел хокук бозулар кылуга җәлеп иткән затның тәкъдимен кире кагу ( килешү) турында мәгълүмат

__________ __________________ __________________

датасы имзасы инициаллары һәм фамилиясе

Татарстан Республикасы тарифлар буенча Дәүләт комитетының 2015 елның 4 июнендәге 150 санлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы тарифлар буенча Дәүләт комитеты дәүләт гражданлык хезмәткәренә коррупциячел хокук бозулар кылуга җәлеп итү максатларында мөрәҗәгать фактлары турында эшкә алучы (эш бирүче) вәкиленә хәбәр итү Тәртибенә 2 кушымта

Татарстан Республикасы тарифлар буенча Дәүләт комитеты
дәүләт гражданлык хезмәткәренә коррупциячел хокук бозулар кылуга җәлеп итү максатларында мөрәҗәгать итү фактлары турында хәбәр итү кәгазьләрен
ТЕРКӘҮ КЕНӘГӘСЕ

| № п/п | Хәбәр итү кәгазенең тәртип саны, көне (талон-уведомлениенең саны һәм көне күрсәтелә) | Хәбәр итү кәгазен җибәргән дәүләт гражданлык хезмәткәре турында мәгълүмат | | | | | Хәбәр итү кәгазен кабул итеп алган затның фамилиясе, исеме, атасының исеме |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | Фамилиясе, исеме, атасының исеме | Шәхесне таныклаучы документ-Россия Федерациясе паспорты, хезмәт таныклыгы | Вазифасы | Контактлар өчен телефон | Хәбәр итү кәгазенең кыскача эчтәлеге | |
| | | | | | | | |
| | | | | | | | |

Татарстан Республикасы тарифлар буенча Дәүләт комитетының 2015 елның 4 июнендә 150 санлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәткәрен коррупциячел хокук бозулар кылуга җәлеп итү максатларында мөрәҗәгать фактлары турында эшкә алучы (эш бирүче) вәкиленә хәбәр итү Тәртибенә 3 кушымта

| ТАЛОН-КОРЕШОК<br>N____<br><br>Хәбәр итү кәгазе алынды | ТАЛОН-УВЕДОМЛЕНИЕ<br>N____<br><br>Хәбәр итү кәгазе алынды |
|---|---|
| | |
| (Дәүләт гражданлык хезмәткәренең фамилиясе, исеме, атасының исеме)<br>Хәбәр итү кәгазенең кыскача эчтәлеге | (Дәүләт гражданлык хезмәткәренең фамилиясе, исеме, атасының исеме)<br>Хәбәр итү кәгазенең кыскача эчтәлеге |
| | |
| | |
| | |
| | |
| | Хәбәр итү кәгазе алынды |
| | |
| ( хәбәр итү кәгазен кабул итеп алган затның имзасы һәм вазифасы)<br><br>"___" 20____ел | ( хәбәр итү кәгазен кабул итеп алган затның вазифасы) |
| | (кенәгә буенча саны)<br><br>"___" 20____ел |
| (талон –уведомление алган затның имзасы )<br><br>"___" 20____ел | ( хәбәр итү кәгазен кабул итеп алган дәүләт гражданлык хезмәткәре имзасы) |